ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ МИНИСТРЛЫГЫ

# Балалар бакчасында татар теле өйрәтү программасы

Казан
2004

УДК 372.3/.4
ББК 74.102
Б 82

Борһанова Р.А., Юсупов Ф.Ф.
Б 82 Балалар бакчасында татар теле өйрәтү программасы. Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгы тарафыннан расланган. - Казань: РИЦ «Школа», 2004. - 84 с.

© Борһанова Р.А., 2004
© Юсупов Ф.Ф., 2004
© РИЦ «Школа», 2004

## АҢЛАТМА ЯЗУЫ

1990 елның 30 августында кабул ителгән суверенлык декларациясе нигезендә татар һәм рус телләре дәүләт теле итеп игълан ителде. Шулай итеп, мәктәпкәчә тәрбия учреждениеләрендә рус һәм башка милләт балаларына татар теле өйрәтү бурычы куелды.

Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгының "Мәктәпкәчә учреждениеләрдә татар, рус, ана телләрен яхшырту чаралары турындагы" 2001 елның июнь аенда чыккан 463 нче номерлы карары нигезендә татар теле өйрәтү дәресләре атнага 3 тапкыр - телне белмәүче балалар белән уртанчылар, ә татар балаларына исә - I кечкенәләр төркеменнән ана теле дәресләре итеп кертү каралган. Шулай итеп, татар теле өйрәтүче тәрбиячеләргә татар телен "Балалар бакчасында татар теле", ә ана телен "Балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү (2000) программалары" нигезендә алып барырга тәкъдим ителгән.

Программаның нигезен коммуникативлык принцибы тәшкил итә Шуңа күрә программа таләп иткән барлык метод һәм алымнар балаларны татар телен аралашу чарасы буларак кулланырга әзерләүгә юнәлдерелә. Программа түбәндәге эш төрләрен һәм бурычларны үз эченә ала.

1. Сүз байлыгын үстерү һәм активлаштыру.
2. Авазларны ишетә һәм аера белергә, шулай ук татар теле өчен генә хас авазларны дөрес итеп әйтергә өйрәтү.
3. Грамматик күнекмәләр формалаштыру.
4. Җөмләләрне дөрес төзергә өйрәтү.
5. Бәйләнешле сөйләм күнекмәләре булдыру.
6. Татар балалар әдәбияты һәм фольклоры белән таныштыру.

7. Татар халык мәдәнияте турында төшенчә бирү.

Программага, хәзерге заман таләпләрен искә алып, социаль-мәдәни компонент кертелде. Татарстан, татар халкының тормыш-көнкүрешендәге үзенчәлекләр, милли кием, бәйрәмнәр, декоратив-гамәли сәнгать үрнәкләре һ.б. белән таныштыру бурычлары күздә тотылды.

Мәктәпкәчә яшьтәге балаларга татар телен өйрәтү аларның билгеле бер күләмдә сүз байлыгын булдырудан башлана. Шуны истә тотып, программада һәр төркем һәм һәр квартал өчен якынча сүзләр исемлеге бирелә. Әлбәттә, балаларның татар телен белү дәрәҗәләренә карап, тәрбияче ул сүзләрнең санын шактый арттыра яки киметә, аларны активлаштыру өстендә эшләүгә өстәмә вакыт бирә ала.

Программада бирелгән якынча сүзләр исемлеге тәрбиячегә квартал саен яки ел ахырында балаларның татар телен аңлау һәм сөйли белү дәрәҗәләрен билгеләү өчен дә ярдәм итәчәк. Һәр дәрестә ничә сүз үзләштерү мәсьәләсен тәрбияче үзе билгели. Шуның белән бергә, дәресләрдән тыш, сүзләрне ныгыту өстендә индивидуаль эшләр дә планлаштыра.

Таныш булмаган һәр сүз дәрес барышында фонематик, лексик, грамматик яктан өйрәтелә, ягъни бала аны авазларының орфоэпик нормасын бозмыйча әйтергә, аның төп мәгънәсен ачык аңларга һәм грамматик конструкцияләрдә куллана белергә тиеш. Шулай ук төркемдә эшләүче төп тәрбияче дә уен вакытларында өйрәнелгән сүзләрне ныгыту өстендә эш алып бара.

Татар теленең аваз төзелешен өйрәткәндә төп игътибар авазларны ишетә һәм аера, аларны дөрес итеп әйтә белү күнекмәләре булдыруга юнәлтелә. Бу бик әһәмиятле. Чөнки күп кенә балаларның сөйләм аппараты инде рус орфоэпиясе нигезендә формалашкан, сузык авазлар (а, о, ы, ө, ү, ә) өлкәсендә шактый зур аерма булуын искә алып эш итәргә кирәк. Менә *а* авазын гына алыйк. Бу авазның әйтелеше һәм сөйләмдә кулланышы зур кыенлыклар тудыра. Хикмәт, әлбәттә, рус телендәге *а* авазының татар телендәге *а* авазыннан сыйфат ягыннан аерылуында гына



түгел, бәлки рус телендәге *а* авазының төрле иҗек шартларында нык редукцияләнеп әйтелүендә.

Тартыклардан бигрәк тә тирән тел артында ясала торган к, г, өрелмәле ч, җ, шулай ук ң һәм v (в) авазларының дөрес әйтелешенә әһәмият бирү таләп ителә.

Татар һәм рус телләрендәге басым, интонация аерымлыклары да игътибардан читтә калмаска тиеш.

Грамматик конструкцияләр, сөйләм үрнәкләре, балаларның яшь үзенчәлекләрен, мөмкинлекләрен, хәзерлек дәрәҗәләрен исәпкә алып тәкъдим ителә.

Әйтергә кирәк, балаларда аеруча тартым конструкциясе, төшем килешендәге исемнәрне куллану зур кыенлык тудыра. Шунлыктан бу материалны өйрәнүгә тәрбияче җитди игътибар итәргә тиеш. Аларны активлаштыру һәм ныгытуга да вакыт күбрәк бирергә кирәк.

Һәр грамматик конструкция һәм сөйләм үрнәге балаларга яхшы таныш булган сүзләр ярдәмендә генә бирелә.

Грамматик конструкцияләрне үзләштерүгә ярдәм итү максатында программада байтак кына уен үрнәкләре дә тәкъдим ителә. Кирәк дип тапса, яңа уеннарны тәрбияче үзе дә иҗат итә ала. Бер үк уенны төрле темаларга яраклаштырып та кулланырга була.

Программа ел фасылларына яки сөйләм эчтәлегенә бәйле булган табышмаклар, мәкаль, әйтемнәр белән танышуны, әкиятләр укуны, җырлар өйрәнүне, рәсемнәр буенча сөйләүне, милли мәдәният белән таныштыруны, дидактик уеннар уйнауны да күздә тота.

Өйрәнелә торган материаллар, башлыча, күрсәтмә әсбаплар, техник чаралар, кайбер очракларда тәрҗемә яки төрле хәрәкәтләр ярдәмендә аңлатылырга тиеш. Соңгы елларда кайбер тәрбиячеләрнең эшләрендә пиктограммалалар, терәк схемалар куллану гамәлгә керде һәм әлеге тәҗрибә уңышлы нәтиҗәләр бирә.

Билгеле булганча, балалар тормышында *уен* зур урын тота. Шуңа күрә программада балаларның татар теле дәресләрендә алган белем һәм күнекмәләрен ныгыту өчен күп төрле уеннар

(сүзле, дидактик, сюжетлы, рольле, хәрәкәтле, һ.б.) тәкъдим ителә . Аларга һәр дәрестә дә мөрәҗәгать итәргә кирәк.

Татар теле дәресләре балаларда икенче телгә кызыксыну уятудан башлана. Бу телгә күнектерү чаралары кулланыла. Тәрбияче, һәр дәрестә рәсемнәр, уенчыклар, һ.б. күрсәтмә җиһазлар күрсәтеп, баланы өйрәнелә торган сүзгә күнектерә. Алдагы дәресләрдә, кабатлау чаралары кулланып, әлеге сүзләрне истә калдырырга ярдәм итә.

Беренче уку елында балаларга иң гади сорауларга бер-ике сүз белән җавап бирү мөһим булса, ә икенче уку елында исә, икеөч сүздән торган җөмләләр, ике-өч җөмләдән торган кечкенә хикәяләр төзү күнекмәләре бирү карала. Шуның белән бергә сүзне бөтен килеш фонематик ишетергә өйрәтү эше дә алып барыла. Аерым предметка карата куела торган сораулар ике төрле итеп бирелә: *Бу нәрсә? Бу курчак. Бу курчакмы? Әйе, бу курчак* һ.б. Җавап алынасы сүз балаларга баштан ук таныш булырга тиеш. Грамматик конструкцияләр, җөмләләр төзү бары тик яхшы үзләштерелгән сүзләр ярдәмендә алып барыла.

Программа балаларның сүзлек запасын даими тулыландыра баруны таләп итә. Бу эш һәр дәрестә 4-5 яңа сүз үзләштерүне күздә тотып оештырыла. Сүзнең дөрес үзләштерелүен даими тикшереп бару мөһим. Механик рәвештә генә отып калу булмасын өчен, һәр сүзгә туры килә торган предметны күрсәтеп, аның исемен әйтергә кушып, шул исемне кулланып, балага төрле вариантта сораулар бирү зарур. Мәсәлән: *Бу нәрсә? Бу алма. Бу алмамы? (груша күрсәтелә). Юк, бу алма түгел, бу груша.* Мондый күнегүләр предметның исемен аңлап үзләштерергә булышалар.

Беренче дәресләрдә үк балаларга сөйләмдә *бу, болар, нәрсә, нәрсәләр, әйе, юк* сүзләрен дөрес куллана белергә өйрәтү башлана.

Балаларга предметларның үзләре яки аларның рәсемнәре, муляжлары күрсәтелә, аерым очракларда гына тәрҗемә ысулына мөрәҗәгать ителә.

Бу нәрсә? – Бу өстәл.
Бу нәрсә? – Бу туп.



Бу нәрсә? – Бу курчак.
Бу нәрсә? – Бу кулмәк.
Бу нәрсә? – Бу әтәч һ.б.

Бу сүзләр үзләштерелеп, сөйләмдә активлаштырылганнан соң гына тәрбияче аларны күплектә әйтергә өйрәтә:

Болар нәрсәләр? – Болар өстәлләр.
Болар нәрсәләр? – Болар туплар.
Болар нәрсәләр? – Болар күлмәкләр.
Болар нәрсәләр? – Болар әтәчләр һ.б.

Әнә шул рәвешчә, беренче дәресләрдә темага туры килә торган предметларның, уенчыкларның исемнәре, аларның сыйфатлары, төсләре үзләштерелә. Әкренләп, алда әйтелгәнчә, тикшерү сораулары куела һәм *әйе, юк* кебек сүзләр актив сөйләмгә кертелә башлый. Алар ярдәмендә гади генә җөмләләр төзү күнегүләре башкарыла.

Бу нәрсә? – Бу курчак.
Ә бу нәрсә? – Бу машина.
Бу курчакмы? – Әйе, бу курчак.
Бу машинамы? – Юк, бу курчак.

*Нәрсә? нәрсәләр?* дигән сораулар ярдәмендә предметларның исемнәре өйрәнелгәннән соң, тәрбияче берничә әйбер (туп, курчак, машина һ.б.) күрсәтеп, сорау куя: "Болар нәрсәләр?" Бала предметны күплек санга куеп җавап бирә: машиналар, курчаклар һ.б. Шуннан соң кыз яки малай рәсеме күрсәтелә: *Бу кем? "Бу малай"* дигән җаваптан соң, кешегә һәрвакыт *кем?* дигән сорау куелуы төшендерелә.

Татар теле дәресләрендә ике тел өчен дә уртак сүзләргә таянып эш итү отышлы. Андый сүзләрне тематик яктан төркемләп куярга, эш барышында аларның санын даими арттыра баруны күздә тотарга кирәк.

Балаларда татар телендә үзара сөйләшү һәм аңлашу өчен җирлек әзерләү максаты белән диалог үрнәкләре дә бирелә. Сораулар гадидән катлаулыга бару принцибына нигезләнә. "Гаилә" темасын үткәндә, мәсәлән, башта балаларның исемнәре, әти-әниләре, туганлык мөнәсәбәтләре ачыклана.

Программада сөйләшү-әңгәмәләрнең дә якынча темат(а)сы күрсәтелә Мондый сөйләшүләрне әледән-әле кабатлап торга һәм искә төшерү күнегүләрен дә башкарырга кирәк. (Һ)әр төркемдә IV кварталда (җәй аенда) өйрәнелгән сүзләрне, сүзтезмәләрен ныгыту, сөйләмдә активлаштыру эше алып барыл(а).

Дәресләрдә шигырьләр, табышмаклар, мәкальләр, әйтемнәрне сәнгатьле итеп, яттан сөйләргә өйрәтүгә дә зур әһәмият (би)релергә тиеш. Аларны, өйрәнелә торган темаларга, ел фасылларына, бәйрәмнәргә бәйләп һәм балаларның татар телен ни дәрәҗәдә белүләренә карап, тәрбияче үзе сайлый. Укыганда яки яңа сөйләргә өйрәнгәндә, тәрбияче төрле иллюстрацияләр, техник чаралар, күрсәтмә әсбаплар белән эш итә. Өйрәнелмәгән сүзләр булган очракта терәк схемалар куллану да отышлы.

Балаларның татар телендә сөйләшү күнекмәләре башка дәресләрдә дә, режим процессларында, спектакльләр карганда, музыка тыңлаганда, төрле уеннар уйнаганда һ.б. төр эшләнлектә ныгыта барылырга тиеш.

Өченче уку елында балалар белән алдагы елларда өйрәнгән сүзләр, темалар катлауландырылып бирелә Темаларга нигезләнеп, грамматик конструкцияләр төзү, бәйләнешле сөйләм теле үстерү өстендә эш алып барыла.

Программага кушымта буларак, балаларның телне үзләштерү дәрәҗәсен ачыклау максатыннан, педагогик диагностика үткәрү һәм аны үткәрү буенча методик киңәшләр бирелә

Балаларга кече яшьтән үк икенче тел өйрәтү - күп көч һәм вакыт сорый торган дәвамлы һәм җаваплы эш. Бу гаять зур һәм катлаулы бурычны тормышка ашыру, тәрбиячеләрдән, бакча мөдирләреннән (башка хезмәткәрләрдән дә) киеренке эш таләп итә.

Уңышлар сезгә



# I УКУ ЕЛЫ.

## I квартал.

"Танышу", "Уенчыклар", "Гаилә", "Яшелчәләр", "Җиләк-җимешләр" дигән темаларга балаларның татар теле буенча гади генә сөйләм күнекмәләрен булдыру.

Аларның тирә-юнь турында күзаллавын киңәйтә бару, югарыда күрсәтелгән темаларга караган сүзләр исәбенә сабыйларның сүз байлыгын арттыру өстендә эшләү, аларда татар телендә сөйләшә башлау теләге уяту. Уенчыклар белән уйнаганда аларның исемнәрен әдәби тел нормаларына туры китереп, татарча кабат-кабат әйттерү. Татарча исемнәре буенча таныш уенчыкларны таба һәм күрсәтә белергә өйрәтү.

Актив үзләштерелүенә ирешү өчен әйбер исемнәренең мәгънәсен аңлату һәм аларны дөрес әйтү күнегүләре эшләү. Иң якын кешеләрнең (әти, әни, әби, бабай, апа, абый, кыз, малай), яраткан уенчыкларның (мәсәлән, курчак, куян, аю, ат, төлке, туп һ.б.), өй һәм өйдәге җиһазларның атамалары (йорт, өй, бүлмә, ишек, тәрәзә, өстәл, урындык һ.б.) исәбенә балаларның сүзлек байлыгын үстерү өстендә эшләү.

Тәрбияче кушуы буенча предметлар һәм уенчыклар арасыннан исеме аталган әйберне табарга яки аның рәсемен күрсәтергә өйрәтү.

Беренче дәресләрдән үк *Синең исемең ничек? Бу нәрсә? Бу кем?* кебек сорауларга җавап кайтарырга өйрәтү. Әлеге сораулар ярдәмендә балаларны бүлмәдәге җиһазларны, уенчыкларны һәм күз алдында еш була торган әйберләрне бер-берсеннән аера белергә һәм эзләп табарга өйрәтү өстендә эшләү.

Туп кайда? - Туп идәндә

Курчак кайда? - Курчак караватта.

*Кем* һәм *нәрсә* алмашлыкларын дөрес кулланырга өйрәтү эшен дәвам иттерү. Балаларга *кем?* дигән сорау алмашлыгының татар телендә бары тик кешеләргә карата гына кулланылуын төшендерү.

Бу кем? - Бу әни.

Бу кем? - Бу әти.